ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

от 04.08.2020 г. Казань № 290/2020

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатында б о е р ы к  б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлектә:

1.3.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3.2. Дәүләт комитетының инвестиция программалары бүлегенең (алга таба – Бүлек) белешмә телефоннары: (843) 221-82-88, (843) 221-82-62, (843) 221-82-83, (843) 221-82-81.»;

1.3.3 пунктчада:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат стендларында һәм Дәүләт комитеты рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3-2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала;»;

алтынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге (аларның реквизитларын һәм аларның рәсми басылып чыгу чыганакларын да күрсәтеп) Дәүләт комитеты рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.»;

1.5 пунктта:

өченче абзацта «муниципаль районның (шәһәр округының) шәһәр яки авыл җирлегендә» сүзләрен «муниципаль районның шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «190-ФЗ номерлы федераль закон» сүзләрен «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 190-ФЗ номерлы федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «210-ФЗ номерлы федераль законның» сүзләрен «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга»;

2 бүлекне яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

3 бүлекнең 3.1 пунктындагы 3.3.1 пунктчаның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 28 сентябрендәге 1728-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршында Татарстан Республикасы электр энергетикасы һәм җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын карау буенча экспертлар советы утырышын әзерләү һәм үткәрү (алга таба – Экспертлар советы, 1728-р номерлы күрсәтмә);»;

5 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына

һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

Административ регламентка 2 нче кушымтада 9 пунктта «398 номерлы боерык белән» сүзләрен «Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының «Дәүләт һәм муниципаль берәмлек катнашындагы оешмаларның, эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен гамәлгә ашыручы оешмаларның энергияне сак куллану һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендәге программасы һәм аларны гамәлгә ашыру барышы турында хисаплылык формасына карата таләпләр раслау хакында» 2014 елның 30 июнендәге 398 номерлы боерыгы белән» сүзләренә алмаштырырга;

Административ регламентка 6 нчы кушымтада «Инвестиция программасын финанслау планы» сүзләрен «Инвестиция программасын гамәлгә ашыруның тариф нәтиҗәләрен исәпләү» сүзләренә алмаштырырга;

(белешмәлек) кушымтада «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты» таблицасында түбәндәге юлны:

| | | |
|---|---|---|
| «Инвестиция программалары бүлегенең әйдәүче киңәшчесе | 221-82-62 | Gulnara.Korchashkina@tatar.ru». |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «Инвестиция программалары бүлеге җитәкчесе | 221-82-88 | Yusupova.A@tatar.ru». |

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның «17» гыйнварындагы 6 номерлы боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның «___»_________ __ номерлы боерыгы редакциясендә)

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең атылышы | Татарстан Республикасы территориясендә җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын раслау | 190-ФЗ номерлы федераль законның 5 статьясындагы 2 өлеше |
| 2.2. Башкарма хакимият органы исеме | Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә |

| | | |
|---|---|---|
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Инвестиция программасын раслау турында Дәүләт комитеты рәсми сайтында бастырылган карар яки инвестиция программасын раслаудан баш тарту һәм аны эшләп бетерү турында Мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән карар | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 5 маендагы 410 номерлы карары белән расланган Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын килештерү һәм раслау кагыйдәләренең, шулай ук мондый программалар (электр энергетикасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә раслана торган шундый программалардан гайре) составына һәм эчтәлегенә карата таләпләрнең (алга таба – Кагыйдәләр) 29 пункты |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать | Дәүләт комитеты:<br>- җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын, инвестиция | Кагыйдәләрнең 34, 45 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) срогы | программасын гамәлгә ашыра башлыйсы чордан алда килгән елның 30 октябренә кадәр раслый. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты Мөрәҗәгать итүче инвестиция программасын раслау турында гариза белән мөрәҗәгать иткән вакыттан башлап 199 календарь көне тәшкил итә;<br>- концессия килешүен төзегән Мөрәҗәгать итүченең инвестиция программаларын концессия килешүе гамәлгә кергән беренче елда тиешле гаризаны һәм инвестиция программасы проектын, шул исәптән эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын раслау өчен җибәргән көннән башлап 30 календарь көне узганчы раслый;<br>- Мөрәҗәгать итүченең инвестиция программасына үзгәрешләр кертү турында тиешле гариза Дәүләт комитетына җибәрелгән елның 20 ноябренә кадәрге срокта җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларына үзгәрешләр кертә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.<br>Инвестиция программасын раслау турындагы карар яисә инвестиция программасын раслаудан баш тарту һәм аны эшләп бетерү зарурлыгы турында дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган карар күчермәсе белән теркәлә торган хатны Мөрәҗәгать итүче күрсәткән ысул (почта буенча, электрон почта адресына) җибәрү аңа кул куелган һәм теркәлгән көннән башлап ике календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла. | |
| 2.5. Норматив хокукый актлар | Гариза (1 нче кушымта). | Кагыйдәләрнең 8, 16, 18 |

| | | |
|---|---|---|
| нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | Гаризага әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында күрсәтелгән документлар һәм материаллар теркәлә.<br>Документларның күчермәләрен, күчермәне билгеләнгән тәртиптә раслау шарты белән, аларның төп нөсхәләре урынына тапшыру рөхсәт ителә.<br>Документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булу - рөхсәт ителми.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын Мөрәҗәгать итүче Дәүләт комитетына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар Мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (ышанычнамә нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәл кылучы зат тарафыннан);<br>кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы аша.<br>Гариза белән документлар шулай ук Мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә дә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре яки Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | пунктлары<br>Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2014 елның 13 августындагы 459/пр номерлы боерыгы (алга таба – 459/пр номерлы боерык) белән расланган Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен гамәлгә ашыра торган оешманың инвестиция программасының киңәш ителә торган формасын тутыру буенча методик күрсәтмәләрнең 1.2 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм Мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган документарны һәм мәгълүматларны тапшыру таләп ителми. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Мөрәҗәгать итүче булып тормаган, әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның документлар белән мөрәҗәгать итүе | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр юк. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |

| | | |
|---|---|---|
| өчен дәүләт пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте, хезмәт күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать тапшырганда яисә дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты | Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы зат (мөрәҗәгать итүче) тарафыннан үзен кабул итүне (хезмәт күрсәтелүне) көтү, шулай ук дәүләт хезмәтеннән файдаланучы зат (мөрәҗәгать итүче) тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән | Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы указының 1 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризасын, шул исәптән электрон рәвештә, теркәү чоры һәм тәртибе | Гариза кергәннән соң бер календарь көне эчендә. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | Дәүләт хезмәте түбәндәгеләр белән җиһазландырылган биналарда күрсәтелә:<br>һаваны кондиционерлау системасы белән;<br>янгынга каршы система белән һәм янгын сүндерү системасы белән;<br>мәгълүмат стенды белән;<br>документларны рәсмиләштерү өчен мебель белән.<br>Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга каршылыксыз үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итә алу мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Инвалидларга һәм хәрәкәт итү мөмкинлекләре чикләнгән затларга дәүләт хезмәтләре күрсәтү яшәү урыны буенча яисә видеоэлемтә аша, интернет аша дистанцион режимда гамәлгә ашырылырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы мәгълүмат Дәүләт комитетына төп керү юлы янында һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләре бүлеге аша керү урынында, Мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның да чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, мәгълүмат такталарында урнаштырыла | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.15. Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^{1}$ статьясында каралган гаризаны (комплекслы | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре:<br>1)документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;<br>2)дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;<br>3)дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт граждан хезмәткәрләре гамәлләренә прецедентлар (нигезләнгән шикаятьләр) булмау;<br>4)Мөрәҗәгать итүченең Дәүләт комитеты белгечләре белән шәхси мөрәҗәгать иткәндә үзара бәйләнешкә керү саны икедән артмый (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Мөрәҗәгать итүче белән эшләү озынлыгы – 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре:<br>Дәүләт комитеты бинасының җәмәгатьчелек транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;<br>Мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итүче белгечләрнең, шулай ук биналарның тиешле санда булуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында Дәүләт комитеты мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында тулы мәгълүмат булуы;<br>гаризаны Интернет челтәрендә Дәүләт комитетының мәгълүмат ресурслары ярдәмендә электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге; | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары |

| | | |
|---|---|---|
| мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән (шул исәптән тулы күләмдә) файдалану мөмкинлеге яки файдалана алмау | дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү;<br>Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында шәхси кабинет аша гариза тапшыру һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу мөмкинлеге (мондый мөмкинлек тудырылганнан соң).<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (алга таба – КФҮ) аша, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза тапшыруны да кертеп, дәүләт хезмәте КФҮ аша күрсәтелми.<br>Мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге юк.<br>Экстерриториаль принцип һәм комплекслы мөрәҗәгать буенча дәүләт хезмәте күрсәтү гамәлгә ашырылмый | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон | Гаризаны, алга таба документларның төп нөсхәләрен күрсәтеп, Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Интернет-кабул итү системасы аша электрон формада тапшыру мөмкинлеге бар (алга таба – Интернет-кабул итү системасы).<br>Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatarstan.ru) аша электрон | |

| | | |
|---|---|---|
| формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | документ формасында гариза бирү мөмкинлеге булдырылганнан соң, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе электрон рәвештә бирелә | |